РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27 октябрь 2025 ел Буа шәһәре № 5-2

«Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлегенең мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль казна учреждениесе турында нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Җир кодексының 11.10 һәм 39.15 статьяларына һәм «Геодезия, картография һәм пространство белешмәләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 18.1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 08 августындагы 317-ФЗ номерлы Федераль закон, «Пространство белешмәләренең илкүләм системасы «Бердәм цифрлы платформасы «Федераль дәүләт Географик мәгълүмат системасы турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 07 июнендәге 1040 номерлы карары, «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2019 елның 22 апрелендәге 6-39 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлегенең мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль казна учреждениесе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 4.1.8 пункт өстәргә:

«4.1.8. Үз функцияләрен тәэмин итү өчен дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системаларын, шулай ук пространство белешмәләренең милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасын файдаланырга.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/, һәм Татарстан

Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Буа муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://buinsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә һәм мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе Р.Р. Камартдинов